КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 31 март г.Казань № 197

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт медицина һәм белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең яңа системаларын кертү турында» 2008 ел, 18 август, 592 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт медицина һәм белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең яңа системаларын кертү турында» 2008 ел, 18 август, 592 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 5 декабрь, 869 нчы; 2009 ел, 2 февраль, 59 нчы; 2010 ел, 1 март, 102 нче; 2010 ел, 14 июль, 564 нче; 2010 ел, 24 август, 675 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1171 нче; 2011 ел, 6 сентябрь, 746 нчы; 2011 ел, 30 ноябрь, 978 нче; 2012 ел, 21 июнь, 537 нче; 2012 ел, 27 ноябрь, 1026 нчы; 2013 ел, 6 февраль, 76 нчы; 2013 ел, 19 февраль, 113 нче; 2013 ел, 2 апрель, 222 нче; 2014 ел, 16 июль, 502 нче; 2016 ел, 26 октябрь, 787 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү буенча дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре өчен 2021 елның 1 гыйнварыннан.»;

6 пункт үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт медицина һәм белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү системаларын билгеләү турындагы нигезләмәдә:

2 пунктның унынчы абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тормышка ашыру өчен бирелгән халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү өлкәсендәге Россия Федерациясе вәкаләтен башкара торган, гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен үтәүче Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре,» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тормышка ашыру өчен бирелгән халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү өлкәсендәге Россия Федерациясе вәкаләтен башкара торган, гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен үтәүче Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре,» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Бу карарның гамәле 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин